**ТУГАН АВЫЛЫМ-ТАШЛЫЯР!**

*Туган авылым Ташлыярның*
*Урамнары чип-чиста.*
*Кешеләре уңган, булган,*
*Үзләре бик тә оста!*
*Мәктәп, садик, медпункт -*
*Болар бар да клубта.*
*Басулар кемдә дисезме?*
*Әлбәттә инде, "Намус"та.*
*Чагылы да бик матур бит,*
*Мәлләсе уш китмәле,*
*Ул юлларны әйтеп тормыйм,*
*Урманы искитмәле.*
*Иген үстерәләр бездә:*
*Бодай, арпа я солы.*
*Ындырда эш кайнап тора,*
*Амбарларыбыз тулы.*
*Авылым бик озын шул,*
*Кешесе дә бик байтак.*
*Сабантуйда җиңүчегә,*
*Бездә бирелә байрак.*
*Бар да эштә, тырыш халык*
*Минем Ташлыярымда.*
*Кешеләре уңган, булган*
*Үзләре бик тә оста!*










# ӘНИЕМ


*Әнием дип тел ачылган,*
*Йөреп киткәндә дә әни.*
*Бәхетле бул, улым, диеп,*
*Яратасың син, Әни!*
*Балам диеп назлап мине,*
*Битләремнән үбәсең.*
*Бәхетле бул,балам, диеп,*
*Кочагыңда йөрткәнсең.*
*Инде менә үсеп җиттем,*
*Иң зур булышчың синең.*
*Яклармын да, саклармын да*
*Сине, кадерлем минем!*
*Синең өчен без әнием,*
*Һаман да шул бәбиләр.*
*Мәңге яшәсәгез иде,*
*Безне үстергән Әниләр!*








АПАМА
Анының исемен ишетүгә,
Алтын яфрак коелды.
Сары көзгә кергәндә,
Бер сабый дөнья күрде.
Мәҗлес булды - исем кушу,
Исеме матур - Инзилә!
Апам чибәр, исеме дә
Бик килешә үзенә.
Рәзил абый белән менә,
Ике ел инде бергә.
Күзләр генә тимәсен,
Изге теләкләр сезгә!
Бәхет, шатлык һәм саулык,
Сиңа туган көнеңдә.
Шундый матур,чибәр булып
Кал син, апам, гомергә!
insta



Э......
Сылу йөзең, көрән күзең,
Акыллы, чибәр үзең.
Куанычны бүлешәсең,
Сер тотар, ачык үзең.
Классташым, гаеп итмә,
Хата китсә ялгыштан.
Мин сине күптән беләмен,
Аермасын язмышлар.
Күпме гайбәт сүзләр йөрде,
Дуслыкны бозалмады.
Тагын шулай гел дус булып
Яшәргә иде әле.
Мин сине гомерем буе,
Тиңләрмен фәрештәгә.
Синең яхшылыкларыңны
Онытмамын гомергә.
Классташым, рәхмәт сиңа,
Һәрвакыт син янымда.
Тагын шулай бергә-бергә
Яшәргә исәп алда.



# Дусларыма

Дусларыма атап язам
Чын йөрәктән шигыремне.
Шундый дуслар янда булу-
Үзе бәхет түгелме?!
Авыр чакта булышалар
Кайгы килсә – юату.
Иртән тору,хәл сорашу,
Шатлыклар уртаклашу.
Һәрвакытта бергә булыйк,
Авыр ми[illegible]арда да[illegible]

Озак еллар аралашу
Булыр тик безнең кулда.
Аерылмыйк, дусларым, без
Үтсә дә күпме еллар.
Дус-тату булыйк һәрчак без,
Көтә безне зур юллар!


***ИЛЬЗИР ИЛЬГИЗОВИЧКА***

***Ильзир абый - ул директор,***
***Мәктәбебез башлыгы.***
***Куянын да үрчетәбез,***
***Сарай тулы тавыгы.***
***Дәресләр тәмамлангач,***
***Йөгерәбез сарайга.***
***Өйрәнгәнең үзең өчен,***
***Кирәк булыр алай да.***
***Куянын да, тавыгын да,***
***Без карарбыз үзебез.***
***Ильзир Ильгизович булганга***
***Ожмахта кебек бит без!***
***Яңа сулыш алдык бит без,***
***Оҗмах безгә бу мәктәп.***
***Ильзир Ильгизовичка бездән,***
***Мең рәхмәт, рәхмәт, рәхмәт!***










ЭЛЬВИНА
Эльвина ул сөйкемле,
Сер тотар, ачык йөзле,
Мөлаем,чибәр үзе,
Киң күңелле, күп сүзле.
Күңелемә керден бит син,
Калырсың гомерлеккә.
Күп еллар күрешмәсәк тә,
Онытмам сине бер дә.
Сиңа алда зур уңышлар,
Бәхет, шатлык һәм саулык.
Мәңге шундый булып кал,
Син бит безнең горурлык!
7-29-17 19:47










**АЛИНӘ**


**Җәйнең матур бер көненд**
**Дөньяга аваз салгансың.**
**Матур исем кушканнар,**
**Алинә  син булгансың.**

**Әти – әниең шатланды,**
**Бәхет туды гаиләдә.**
**Бәхетле бул, кызым, дие**
**Иркәли дә,назлыйда.**

**Исемең җисеменә туры ки**
**Шундый матур, сөйкемле**
**Әти – әниең куанычы булы**
**Алинә, бул  бәхетле!**







# ЭХ, ТАТАР ЕГЕТЛӘРЕ!

***Эх, татар егетләре!***
***Алар ут кебекләре.***
***Баскан жирдә ут чыгара***
***Бу татар егетләре!***
***Безнең татар егетләре***
***Оста, көчле үзләре.***
***Баскан җирдә ут чыгара***
***Бу татар егетләре!***
***Утта янмый, суда батмый,***
***Гөрләшеп яшик әле.***
***Баскан жирдә ут чыгара***
***Бу татар егетләре!***



**АВЫЛЫМ ЯШЬЛӘРЕ**

Ташлыярымның яшьләре,
Авылымны кутәрә.
Гармун сузмасалар да ,
Күңелләре җилкенә.
Биилә р дә, жырлыйлар да
Кул -аяклар арганчы.
Хәзер клубта тугел бит,
«Пати»да җыеннары.
Яшьләр минем авылымда
Бар яктан да уңганнар.
Нәрсәгә тотынсалар да
Булдыра торганнардан.
Сезгә барыр юлыгызда
Уңышлар юлдаш булсын.
Авылыбызда яшьләр калсын,
Ташлыяр гөрләп торсын.








**УКЫТУЧЫЛАРЫБЫЗГА**

Безнең мәктәп коллективы,
Үзе зур, үзе бердәм.
Барсына да җитешәләр,
Коллективыбыз эшчән.
Егерме укытучы
Йөз баланы укыта.
Зур тырышлыклар куеп,
Олы юлга озата.
Укытучыларны без
Хөрмәт итик, яратыйк.
Гомер буе белем биргән,
Алардан  үрнәк алыйк.
Эшегездә зур уңышлар,
Укытучылар, сезгә!
Күп нәрсәгә өйрәттегез,
Мәңге рәхмәт гомергә!






**ПЕШЕКЧЕ АПАБЫЗ**


**Безнең пешекче апабыз,**
**Гөләндәм апа була,**
**Тәмле ашап тамак туя**
**Вот пешереп тә куя.**

**Пешекчебезнең безнең**
**Эшләү теләге зурдан.**
**Эшен җиренә җиткерә,**
**Бәлки кулы алтыннан?**

**Гөләндәм апага без**
**Зур уңышлар телибез.**
**Һәрвакыт шулай тәмле**
**Пешерсен иде дибез!**







Туй көнегез белән!
Бүген,нинди көн диябез.
Кавышу көне сезнең!
Сезнең өчен шатланабыз,
Елмаю йөздә безнең!

Кавышалар пар күгәрчен,
Пар балдак кия алар.
Мәхәббәт телибезз сезгә
Бәхетле булсын парлар!

Мәҗлес бүген,туй көне ,
Бәхетле парлар төне.
Бар да Бәйрәм итәләр
Бүген бит кавышу көне!

Абый,апам пар аккоштай,
Йөзегез гомер юлсын.
Бергә янәшә булсагыз,
Булдермәс көчле дулкын!



ӘЙ ГАРМУНЫМ!

Әй син гармун дигәннәре,
Уйна әле, бер сыздыр.
Матур көйләр көйлә әйдә,
Эчең моң белән тулы.

Күңелемне күтәрәсең
Моңсу булган вакытта
Биетәсең,җырлатасың,
Безне юатасың да.

Гармун кулда чакта әйдә,
Уйна әле сыздырып.
Елатсын да,җырлатсын да
Күңелләрне кузгатып.





**Ташлыярым-Туган Төбәгем!**

*-Газиз ягым-Ташлыяр.*
*Туган җирләр,басулар*
*Бездә генә шулай матурдыр ул,*
*Кара урман,ул болыннар!*

*Мәллә ага челтер-челтер,*
*Кушыла аннан Ыкка.*
*Бәлки бездә генә кебектер,*
*Халыкның иң татуы да.*


*Ул басулар бездә,колач җәя,*
*Каршы ала һәммәсен.*
*Безнең авылга килмәсәң,*
*Ялгыш булыр,бел шунсын!*

*-Чишмәседә бездә,иң шифасы,*
*Күнелгә дәва бирә.*
*Безнең якларга килсәң син,*
*Авыз итми,һич китмә.*

*Сабантуйлар шыгрым халык,*
*Яна еллар шәп утә.*
*Синдә безнең бәйрәмнәрне*
*Карамыйча һич китмә!*

*Чагыл таулары да бездә,*
*Иң олы таулар кебек.*
*Хәлең бетә җәяү барсаң,*
*Менеп җитеп булмас кебек.*




-Ул күлләре дә бездә,
Чистанын чисталары.
Балык тотарга кил син безгә,
Табан,күкин,йә чуртанны!

Кешеләр дә безнең якта,
Җылы каршы алырлар.
ый нигмәтләр белән өстәл тула
Чәк-чәк,бәлеш ул кыстыбыйлар

-Кайсы яктан карыйм димә,
Безнең яклар иң шәбе!
Әйдәә иптәш,син дә бу якларга.
Бер килеп кит әле!





Тойгелде җирлеге дияләр,

Тойгелде җирлеге дияләр,
Мөслим чатында тора.
йгелде,Игенче,Атлас Ташлыяр,
Дус,тату халык монда!

Бергә утә кичәләр дә,
Рәхәт безгә монда дим.
Сельсовет тота авылны,
Дамир абый Мәүҗетдин!

Уты,суы кергән бездә,
Һәр ойдә тора кеше.
Дүрт авылны бергә кушсак
Мең ике йөзлэп кеше.

Тойгелде җирлеге дияләр,
Тиңнэр юк кебек ана.
ын шулай бердәм,дус булып без,
Яшәргә исәп,Алда!

**Мәхәббәт хакында**

*Мәхәббәт бирәү булса да,*
*Яши ике йөрәктә,*
*Үз парыңны таба алу*
*Насыйп булсын һәркемгә.*
*Мәхәббәт белән бәхет*
*Икесе гел янәшә.*
*үзләр - күздә,сүзләр - уртак,*
*Ике йөрәк серләшә.*

*Күзләреңә бер карыймын,*
*Сагынган чакларымда.*
*Үкенергә кирәк түгел,*
*Яраткан чакларыңда.*








**КӨЗ**

**Көзгә аяк басабыз бит,**
**Яз, җәйләрне озатып.**
**Алтын яфрак лар коела ,**
**Торабыз хәйран калып.**

**Көзгә керик сау –сәламәт,**
**Көздән без көч,дәрт алыйк.**
**Матур уйлар белән генә**
**Алтын көзне каршылыйк.**

**Көз  ул – уңыш,муллык чоры,**
**Бәрәкәте белән килсен.**
**Кайгыларны юк итсен ул,**
**Шатлык,бәхет китерсен.**

**Көзгә аяк басканда без,**
**Яхшыга өмет итик.**
**Дус, туганнар белән бергә**
**Яшик,яшьник, гөрләшик!**



**ЛИЛИЯ**

**Лилия исеме матур бит,**
**Әллә каян ишетәм.**
**Ул лилия чәчкәләрен**
**Мин яратам һәм сөям.**

**Лилия исеме нинди бит,**
**Үзе матур яңгырый.**
**Чәчкәләре дә ни тора?!**
**Яратудан дәвалый.**

**Лилия исеме матур бит,**
**Ныклы, зәвыклы исем.**
**Лилияләрне яратып ,**
**Яшәргә насыйп итсен!**






## Яңа ел

Яңа ел житә, дусларым,
Яңа биттән башлана,
Яңа сулыш, дәрт- дәрманнар
Яңа уйлар уйлана.

Яңа бәхет, шатлык телим
Яңа елда һәркемгә.
Яңа 2018 дә
Изге теләкләр сезгә!



Күпме яңа дигән сүз бит,
Болар бар да сезнеке.
Яңа сулыш, яңа бәхет
Булыр бары безнеке!



ХӘЕРЛЕ ИРТӘ!

Уяндыңмы, сәлам бир син,
Бар белгән дус , туганга.
Хәерле иртә теләргә
Онытма якыннарга.
Саумы кояш,сүнмәс учак,
Ак болытлар зәңгәр күктә,
Урман-кырлар,чишмә-таулар -
Барсына да хәерле иртә!
Бар да көләч, шат булсыннар,
Булсыннар гел бәхетле.
Хәерле иртә белән дип,
Теләкләр телим әле.




*Изге Вәли көне җитте,*
*Бәхетле парлар көне.*
*Бәхет,шатлык һәм мәхәббәт*
*Юлдаш булсын,гомер гомерне*

*Иң зур бүлэк,бәлки синдер,*
*Диеп дәшсеннәр әле.*
*Бу көн барлык парлыларга,*
*Бәхет китерсен әле.*

*Изге Вәли көнендә туа,*
*Чын мәхәббәт хисләре*
*Мөбәрәк кенә була күрсен*
*Изге Вәли көннәре!*



***Истәлек***

***Салмак кына,җилләр исә,***
***Уйный ап-ак бураннар.***
***Җиргә төшеп күзәтәдер,***
***Безне киткән туганнар.***

***Тәнгә төшеп куналардыр,***
***Тоелсын өчен җылы.***
***Күңелләрдә безнең шул чак,***
***Саф хәтирә,саф тойгы.***

***Киткән инде мәңге кайтмас***
***Булсын урыннар түрдә***
***Мәңге хәтирә,сагыштыр***
***Безнең күңелләребездә***

## Сәламләү

Исәнмесез,саумысез
Хәерле кичләр сезгә
Бер күңел ачыйк әле
Зур бәйрәм бүген бездә!

Олысыда ,кечеседә
Бәйрәм көтә бар халык
Безнең җырлау һәм биюгә
Торсыннар хәйран калып

Ташлыярым бәйрәм итә
Бүген булыр бик кызу
Шәп кәеф,дәрт буләккә
Булыр куллар кып кызу

Концертыбыз башлана
Залдан тынлык сорала
Без жырларбыз,биербез дә
Кул чабу сездән тора!






**2018 сайлулары**

Сайлаулар житә бит әле
Президент сайлаулары.
Путин,Грудинин кебекләр
Президент кандидатлары

Һәр кемнең дә үз фикере
Һәр кемнең үз теләге.
Кайсын сайласа да инде
Үзенә бит кирәкле.

Сайлаганда дорес сайлый
Безгә бик кирәклесен.
Халык кайсын сайлар инде б
Әлбәттә кирәклесен!








**Үткәннәргә,юк,карамыйм...**

*Үткәннәргә,юк,карамыйм,*
*Сагыш биләп алса күңелне,*
*Анда калган,искә алмыйм,*
*Бәхетле мизгелләрне.*

*Алга атлыйм,гомер сукмагыннан,*
*Алда көтә мине зур юллар,*
*Үземә мин кинәт әйтеп куям*
*Булмас сагыш,булмас ялгышлар*

*Кинәт искә төшә,шул вакытлар*
*Яман була,искә алулар*
*Ләкин бер ни әшләп булмас кебек*
*Уткәннәргә бит,юк юллар...*

Елның иң матур фасылы
Килә матур ,сылу яз
Җир шарын,чәчкәгә күмәдер
Күңелгә тула бит наз

Кошлар кайта ,чәчәк ата
Шомырт,юкә ,алмагач
Бу дөньяның рәхәте кая соң?
Күңелдә яз булмагач.

Яңа илһам,яңа сулыш
Яңа дәрттә,яңа наз
Бар җирне ямьгә кумәдер
Дөньяга килә бит яз!

Туган көнең белән!
Туган көнең синең бүген
Барда бәйрәм итсеннәр
Бәхет,шатлык ,һәм дә саулык
Сиңа тик теләсеннәр




Миндә теләп китим әле
Теләкнең иң изгесен
Озын гомер яшәп сау
саләмәт
Үт кенә гомер юлын

Күнелең яшь,дәртләнеп
тор
Күрсәт лә күрмәгәнен
Шатлыкка,дәрткә
күмелеп
Үтсен синең бу көнең

Туган көнең бүген синең
Чиге юк теләкләрнең
Йөзәр ел буе яшә син
Картаймасын күңелең






Язның бер матур көнендә.
Шау шу туды дөньяга!
Бар җир шарын кузгатты ул,
Гомер булмаган бәла.


Пожар чыккан,үләләр ди!
50,60,80ннәр.
Кая бара бу дөньябыз?!
Пожар,үлә балалар!

Ни караган җитәкчесе?!
Нигә болай була сон?!
Бер гаепсез сабыйлар,
Янып үлә,нигә сон?!

Ишекләр нигә ябылган ?!
Янгын нидән кабынган?!
Нигә гәепсез эти энилэр,
Балаларын югалткан?!

65кеше ,нинди сан бит!
Янып үлә пожарда.
Мондый фаҗига булмасын,
Йә сакласын син,Әй Аллам!

- ДҮРТЬЮЛЛЫКЛАР


***
Кем күтәрә
авылымны?
Ачык йөзле, шат
халык.
Кечесеннән,
олысыннан
Дәрт - дәрман тора
ташып

***

Җир белән күк арасы,
Эх, бер барып
карыйсы...
Кояшны да ерак диләр,
Ялгандыр бу, ахрысы.




***

Ап-ак кардай була күрсен

Безнең барасы юллар.

Кая барма, кая китмә -

Телим бары уңышлар.


Парлы чия алдым
кулга,
Теләдем теләкләрен.
Теләкләр кабул булыр
дип,
Ышанды йөрәккәем!

***


Күккә карап
сокланамын,
Күренә яктылыгы.
Әллә анда ожмахларга,
Ачыкмы керер ягы?


Бөек Ватан
елларында,
Кырда калган күпме
җан.
Аларга ул еллар өчен,
Мәңге рәхмәт һәм зур
дан!
ОНИ
ВЕРНУЛИСЬ
С
ПОБЕДОЙ




***

Изге йортка аяк бастым,
Кабул булыр догалар.
Арабыздан кон дә китә!
Күккә китә туганнар...

***

Дөньяларны яктыртырга,
Күктә яна якты ай.
Нәкъ авылым уртасында
Балкып тора ярым ай


ПАРЛЫ ЧИЯ
АЛДЫМ КУЛГА...

Әнием
Әтием
Апаем
Инзилә апам
Азат абый
Шамиль абый
Зилэ
Алсу
Илүзә
Рөстәм
Камиль
Рафил
Ильсур
Алина
Данир
Эльвинчик
Шамс Айрат
Деня-Динар
Айзиля
Гузэл
Тансылу
Ильзир
Ильгизович+тормыш иптэше

Эльвина
Алина
Альбина
Айзиля
Динар
Язиля
Данис
Лиана
Адель
Алия
Зэйнэп
Ильяс
Алмаз
Эльмира.Р
Чулпан.Р
Лилия.Ф
Марат.С
Анастасия.А
Ольга.Н
Гольназ.Р
Рамиля.Г
Хэмдия.Ф
Резеда.Я
Ильсур.И

Эльмира.Ф
Лилия.З
Юлья.Г
Айгуль.Ф
Голэндэм апа
Соня апа
Ринат абый
Федька
Рэзил абый
Юлия апа+Иван бажай
Эдик абый+хатыны
Христина апа+Алеша абый
Нэркис абый+Золфия апа
Мария тутэй+Юра абый
Люда апа+ире
Айсылу
Золфия
Йолдыз
Настя
Монзилэ апа
Алия(2)

Лилия

3 сен 2017

21:43

Алина

4 сен 2017

17:07

Инзиля

13 сен 2017
16:39

Ильзир Ильгизовичка

14 сен 2017 14:29

Альбинаga

15 сен 2017
17:25

Эльвинәгә

19 сен 2017

19:01


Эхх,Татәр
егетлэре
19 сен 2017
20:54

Мэхэббэт

20 сен 2017

21:02

Эхх,Гәрмуным

20 сен 2017

18:09

Коз

23 окт 2017


16:27

23 окт 2017

22:47

Авылымның

Яшьләре


Дусларымааа
20 нояб 2017
20:39

Янә еллл

31 дек 2017

13:36


Хэерле иртэ

14 янв 2018
13:47

Э******

14 янв 2018

13:48


Изге Вэли
14 февр 2018
7:08

2018 сәйлауләры

16 февр 2018

0:00

Уткэннэргэ,
юк, карамыйм

16 февр 2018
0:03


16 февр 2018
0:06
Жирлегә
диялэр...


Сэлэмлэу
16 февр 2018
0:07

Истэлек...

7 мәрт 2018
18:14

7 март 2018

18:19

Туган Ягым-Ташлыяр

18 мәрт 2018

21:05

Туй конегез

белээн

Тугән конен белэн

31 мәрт 2018

0:13

Доньягә бит
яз килэ...

31 мәрт 2018
0:14

Кемерово

25.03.2018

31 мәрт 2018

0:07

23 әвг 2017

...

Ташлыярым!

23 әвг 2017

...

Әнием


4 окт 2017

...

Укытучыләры бызгә

4 окт 2017

... Пешекче әпәбыз



Игътибарыгыз очен рэхмэт!

Thank you for your attention !!!

Спасибо за внимание!